Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№19 (70)
6 июнь 2013 ел

**• Вакыйгалар эзеннән**

4 июнь көнне ректор **И.ГАФУРОВ** житәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Административ эшләр буенча проректор – аппарат житәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм айлык чаралар планы белән таныштырды. Бу уңайдан, ректор 23 июньдә узачак зур чарага – Планетарий ачылуга басым ясады. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** университетның РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча конкурсында катнашуга әзерлеге турында мәгълүмат белән таныштырды. Тагын бер кат өстенлекле юнәлешләрне, статистика формаларын тикшереп чыгасы бар. КФУның Ботаник бакчасы турында Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.КИЯСОВ** чыгыш ясады. Ботаник бакча территориясе 150 га жирне биләп тора. Ул берничә зонага бүленә: укыту, кунакларны каршы алу һәм форумнар үткәрү, спорт-парк базалары. Аларда төрле чаралар уздырып, Кызыл китапка кертелгән үсемлекләрне үстереп булыр иде.Ректор И.Гафуров та үз фикерләре белән уртаклашып: «Президент Р.Миңнеханов та бу проект белән таныш. Без аны шәһәр, республика белән бергә тормышка ашырачакбыз, ләкин ул безнең шәхси милек булып калачак», – диде. Идарә итү һәм территориаль үсеш институты директоры **Н.БАҺАВЕТДИНОВА** институт базасында ачылачак территориаль-икътисади үсешне анализлау һәм прогнозлау лабораториясен ачу турында мәгълүмат житкерде. Ул КФУның шушы институт һәм РФ Фәннәр Академиясенең халык-хужалык прогнозлаштыру институты белән килешү кысаларында ачылачак.

• • • •

Шушы көннәрдә Яр Чаллының икътисад факультеты деканы, икътисад фәннәре докторы **А.МАКАРОВ** V Халыкара фәнни-гамәли **«ТӨБӘКНЕҢ ЯҢАДАН ЭШКӘРТҮ ПОТЕНЦИАЛЫ»** (Башкорт дәүләт университетында үткәрелгән) исемле **КОНФЕРЕНЦИЯДӘ** катнашты. Конференция вакытында ике уку йорты арасында килешүгә кул куелды.

• • • •

1 июнь көнне **КФУ РЕКТОРЫ И.ГАФУРОВ** Апас районында узган **БАЛАЛАР САБАНТУЕНДА КАТНАШТЫ**. Халыкара балалар көненә багышланган чарага 2 меңнән артык бала җыелды. Тәбрикләү сүзендә И.Гафуров балаларны бәйрәм белән котлады, күңелле каникуллар теләде һәм федераль университетка чакырды. КФУ ректоры исеменнән яхшы укучыларга һәм спортсменнарга бүләкләр тапшырылды.

• • • •

Шушы көннәрдә Яр Чаллы институтында **«ЭТИКАЛЫЛЫК, МИГРАЦИЯ ҺӘМ ХАКИМИЯТ: XXI ГАСЫР КАРШЫЛЫКЛАРЫ»** Халыкара фәнни симпозиум булды. Яр Чаллы институты, А.С.Пушкин ис. Брест дәүләт университеты (Белоруcия республикасы) һәм Россия сәяси фәннәр ассоциациясенең Татарстан бүлеге оештырган симпозиумда РФ, Белоруcия, Испания, АКШтан 40ка якын галим катнашты.

• • • •

30 май-2 июнь көннәрендә Мәскәүдә студентлар арасында **3х3 БАСКЕТБОЛ** буенча **РОССИЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ УЗДЫ**. Бәйгедә бөтен Россиядән 48 ир-ат һәм 24 хатын-кыз командалары катнашты. Алар арасында КФУдан да хатын-кызлар командасы бар. Ул хатын-кызлар турнирында җиңүгә иреште. Алар Голландиядә үтәчәк студентлар арасында Европа чемпионатында Россия өчен уйнаячаклар.

• • • •

3 июньдә **КФУның АЛАБУГА ИНСТИТУТЫНА** Европа төбәкләре ассамблеясенең генераль сәркатибе **ПАСКАЛЬ ГЁРГЕН КИЛДЕ**. Алабуга институты белән таныштырылды, ноябрь аенда уздырылачак VI Халыкара «Россиянең кече шәһәрләре: үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге» Стахеев укуларының оештыру моментлары турында фикер алыштылар.

• • • •

8 июнь көнне Казан IT-паркында КФУ ИТИС югары мәктәбенең **АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ** булачак. Теркәү сәгать 11дә башлана.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Киң палитра булдырдык!

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

Быел Казан федераль университетында май-июнь айлары өчен гадәти күренеш булган студентлар тавышы да янгырамый, сессия рухы да аңкып тормый,ниндидер бушлык сизелә. Әмма бу озакка түгел, чөнки бик тиздән университет үзенең булачак студентларына ишекләрен ачачак.

Быел Кабул итү комиссиясе Федераль законнар җыелмасы нигезендә 20 июньдә үз эшчәнлеген башлап җибәрәчәк. Россиянең барлык югары уку йортларында кебек үк, КФУда 25 июльгә кадәр 35 көн буе абитуриентлардан документлар кабул ителәчәк.

«Быел бездә бакалавр, белгечлек, магистратурага 442 конкурслы төркем каралган. Бюджетлы урыннарның саны – 4995 һәм якынча шуның кадәр үк контрактлы урыннар исәпләнә. Быел барлыгы 10 меңләп кеше кабул итәргә ниятлибез. Узган ел бу күрсәткеч 10500 иде. Бүгенге көндә уку йортыбызда 50 меңгә якын студент белем ала», – диде Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **Сергей Ионенко**.

Кабул итү төп югары уку йортының 20 институтында һәм 4 филиал: Яр Чаллы, Алабуга, Яшел Үзән, Чистай институтларында башкарылачак. КФУ абитуриентларга чиксез мөмкинлекләр тәкъдим итә ала, ул чын мәгънәсендә белем бирү формаларының киң палитрасына ия булган уку йорты. Мисал өчен, биредә бакалавр, белгеч, магистр, урта һөнәри белем алу базасында кыскартылган программалар (Яр Чаллы институтында 11 юнәлеш буенча югары булмаган һөнәри белем бирәләр. Анда 9 һәм 11 сыйныфтан соң укырга керергә мөмкинлек бирелә) һәм икенче югары белем бирү программалары бар.

Яңа уку елы үзе белән күп кенә яңалыклар да алып киләчәк. Үзгәрешләрнең иң мөһиме һәм әһәмиятлесе – яңа белгечлекләр ачылу. 1930 елдан бирле, университетыбызда медицина буенча укыту тукталып торганнан соң, әлеге юнәлеш яңадан кире кайтарыла. Өстәвенә, ул бик сыйфатлы һәм яңа дәрәҗәдә башкарылачак. Анда табибтикшерүчеләрне әзерләячәкләр. Шулай ук инженерия юнәлеше буенча да киң спектрлы белгечлекләр ачылачак. Бу – безнең уку йорты өчен тулысынча яңа юнәлеш. Элеккеге Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясендә эшләп килгән әлеге бүлек тулаем үзгәртелеп, автомобиль инжинирингының югары мәктәбе булып оешып житте. Анда бу өлкәгә кагылышлы барлык белгечләр, шул исәптән, дизайнер, конструкторлар, сату итү буенча белгечләрне дә әзерләячәкләр. Алар Алабуга, Түбән Кама, Яр Чаллы класстерына хезмәт күрсәтәчәк. Төп вузда да инженерия институты ачылачак.

**Ахыры 2нче биттә.**

**• Фән дөньясында**

# Европа белән бәйләнеш урнашты

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Диана Поварова фотосы

4 июньдә КФУда «Территориянең тотрыклы үсеше белән нәтиҗәле идарә итү» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция ачылды. Ачылу тантанасында ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм Европа төбәкләре Ассамблеясе Генераль сәркатибе Паскаль Гёрген (*фотода*) катнашты.

Нәтиҗәле идарә дигәндә, территориянең җирле халык таләпләрен канәгатьләндерүгә сәләтле, киләчәк буыннарга да житәрлек балансы үсеше һәм конкурентлыкка сәләтле лидерлыгын күз алдында тоту кирәк. Моңа ничек ирешергә? Әлеге сорауга җавапны конференциянең тематик секцияләрендә төрле яклап эзләделәр. Катнашучыларны сәламләп, **И.Гафуров** күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеген ассызыклады һәм аларның университет эшчәнлегендә чагылышы хакында сөйләп узды. «Фәнни-мәгариф учреждениеләре, хакимият, бизнес арасындагы яңа форматлы мөнәсәбәтләр җәмгыятьнең тотрыклы үсешенә турыдан-туры тәэсир итәргә мөмкин. Бүген университетыбызның төп максаты: төбәкнең социаль-икътисади үсешенә ярдәм итү, конкурентлыкка сәләтлелекне арттыру.

**Ахыры 2нче биттә.**

• Яңа китап

Шушы көннәрдә генә яраткан шагыйребез, язучы, драматург, балалар язучысы һәм үткен публицист Фәнис Яруллинның «Хәтер төпләрендә утлы күмер» исемле китабы дөнья күрде. Анда Фәнис абыебызның шигырьләре дә, хикәя-повестьлары да урын алмаган. Бу китапка авторның аерым шәхесләргә, тормышка, дөньяда барган вакыйгаларга карата үз кичерешләрен, үз уй-фикерләрен чагылдырган көндәлекләре тупланган.




# Хәтер төпләрендә утлы күмер



Аның әдәби эшчәнлеге үзенчәлекләреннән берсе төрле жанрларда иҗат итү булса, икенчесе - авторның геройлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең тирән драматизм белән сурәтләнеп, нечкә психологик алымнар белән чишелүдә. Ул, беренче әсәрләреннән үк диярлек, шул вакыттагы рәсми идеология кануннарына буйсындырылган әдәби юнәлешкә бик үк туры килеп бетмәгән мәсьәләләр күтәрә башлый һәм алга таба әлеге тенденцияләр аның иҗатында көчәйгәннән-көчәя бара. Ф.Яруллин әсәрләрен тормышның тышкы конфликтларыннан чыгып түгел, вакыйга-күренешләрне күңелдә туган хис һәм кичерешләргә бәйләп, аны үз иманы аша үткәреп, тормыш каршылыклары белән бәрелештә сурәтләде, герой язмышын алгы планга куйды.

Югары эстетик зәвыкка ия булган күпкырлы талант иясе Фәнис Яруллин, нинди генә жанрда язмасын, үз әсәрләрендә матурлыкны, камиллеккә омтылышны һәм рухи байлыкны иң зур кыйммәтләрдән санады. Үзенең укучыларына да шушы идеяне җиткерергә омтылды.

Хөрмәтле укучыларыбыз, сезнең игътибарга әлеге китаптан өзек тәкъдим итәбез.

1958 ел, 17 июль. Красноярск краеның Канский шәһәре. Мин шунда хәрби шәһәрчектә укчы радистлыкка укып йөрим. Спорт белән шөгыльләнәм, парашюттан сикерәм, һәм 17 июльнең ул край вакыты белән кичке сәгать 9лар тирәсендә кинәт билгесезлеккә очам. Бары тик хәрби санчастьнең каты топчанында гына аңга киләм. Күзләремне ачканда, ике пар күз миңа карап тора иде.

- Су! - дидем беренче сүз итеп һәм кызлар кулындагы стаканга үрелмәкче булдым. Шунда гына кулларымның миңа буйсынмавын аңладым.

Кызларның берсе, кулын минем баш астына тыгып, башны калкытмакчы булды.

Мин:

- Алла! - дип кычкырып җибәрдем.

- Син татармы әллә? - дип сорады берсе.

Мин керфек кагып кына җавап бирдем. Аннары кызлар сузып торган стаканнан берике йотым су эчтем. Муенның сызлавына чыдар хәл юк. Җитмәсә, санчастьның ятагы каты, бүлмәсе бөркү. Кызлар, минем хәлне аңлап, мине чишендерә башладылар. Муен тирәсенә куллары якынлаша башласа - кычкырып җибәрәм.

Бу кызлар медчастьтагы дежур медсестралар булып чыкты. Берсе минем күт битенә укол чәпәде. 10-15 минутлар үтүгә, авыртуым бераз басыла төште. Кызлар да минем белән шаярып сөйләшә башладылар.

- Чибәр егет, нишләп моңарчы безгә бер дә килмәдең?

- Менә иртәгедән килеп йөри башлармын инде. Ләкин кайсыгыз янына килергә соң?

- Кайсыбызны ошатасың - шуңа инде. Кызлар, халатларын салып, каршыма бастылар. Аларның икесе дә миңа бик чибәр күренде. Армиядә кызларга сусап торасың, бәлки, шуңа алар миңа чибәр күренгәндер.

- Сез икегез дә миңа бик ошыйсыз. Ике колактагы пар алкалар кебек.

- Алайса икебез янына да килерсең.

- Мондый чибәрләрнең егетләре күптер шул. Кабыргаларыңны санап җибәрерләр.

- Санаттырмабыз! - диләр кызлар.

- Алайса, иртәгә мин сезнең янда булырмын.

Мин ул чакта әле гомерлеккә урын өстендә ятып калырмын дип уйламыйм, менә-менә муенымның авыртуы бетәр дә аякка басармын дип уйлый идем.

*Бик күп вакыйгалар*
*Керми әсәрләргә –*
*Көндәлекләр булып*
*Ята дәфтәрләрдә.*

*Тик алар да әле*
*Барсын сыйдыра алмый.*
*Язмыш елагалары*
*Ага кайный-кайный.*

*Кала бозлар утырып*
*Күңел ярларында.*
*Тормышның иң чыны –*
*Бары җаннарымда.*

*Ә җаннарны һич тә*
*Булмый киереп ачып.*
*Яшибез гел шулай*
*Үзебездән качып.*

*(Ф. Яруллин)*

• Абитуриентлар өчен

# Киң палитра булдырдык!

**Башы 1нче биттә.**

Быел абитуриентларны кабул итү федераль мәгълүмати система буенча гамәлгә ашырылачак. РФ хөкүмәте һәм Россия мәгарифе надзорының әмере буенча, 2013 елдан барлык вузлар да үзләренең мәгълүматларын федераль мәгълүмати системага тапшырырга тиеш. Әлеге системага КФУ да кергән, җиһазлар көйләнгән. 2012 елның мәгълүматлары инде җибәрелеп, хәзерге вакытта яңадан тикшерү үтәләр. Россиянең 99 процент югары уку йортлары әлеге системага кергән. Быелдан Казан федераль университеты да документларны тапшырган абитуриентлар турындагы мәгълүматны көн саен шунда җибәреп торачак.

2013-2014 уку елында Казан университетында кичке уку бүлегенә студентлар кабул ителмәячәк. Бу әлеге төр укуга ихтыяҗ булмаганлык белән аңлатыла.

Һәркемне борчыган һәм иң зур кызыксыну тудырган мәсьәлә – түләүле бүлекләрнең бәясе. «Нигездә, университет быел бәяләрне әллә ни кискен күтәрмәде. Кайсыдыр бүлекләрдә зур үзгәрешләр булса да, алар мәгариф һәм фән министрлыгы нормативлары белән бәйле. Хәзер уку-укыту процессы Мәскәү тарафыннан билгеләнә. Узган елдан башлап, бездә яңа «Студентлар белгечлекләрен әзерләү юнәлеше буенча финанслау нормативлары» программасы кертелде. Мисалга булачак инженер якынча 130 меңгә укырга тиеш дип алыйк. Дәүләт бер инженерны әзерләү өчен, шуның кадәр акча түгә. Бу логикадан чыгып, без дә түләүле бүлеккә 130 меңнән дә кимрәк бәя куя алмыйбыз. Шунысын әйтергә кирәк: түләү бәясе югары бүлекләрдә бюджетлы урыннар да күбрәк була», – дип билгеләп үтте **Сергей Ионенко**.

Университет шундый үзгәрешләр белән абитуриентларны кабул итәргә әзерләнә. Документларны узган елдагыча, шәхсән үзең килеп, почта аркылы яисә КФУның сайты аша тапшырырга мөмкин.

• Фән дөньясында

# Европа белән бәйләнеш урнашты

**Башы 1нче биттә.**

Моның өчен, беренче чиратта, төрле территорияләрдә, хакимиятнең төрле үсеш баскычларында эшли алырлык белгечләр әзерләү кирәк», – диде ул үз чыгышында. Фәрит Мөхәммәтшин дә вакыйганың мөһимлеген билгеләп узды. Ул Татарстан үсешенә ярдәм итә торган проектлар белән таныштырды. (Иннополис буенча проект, «СМАРТ Сити Казан» проекты). Гёрген әфәнде исә, үз чиратында, Татарстан һәм Казан университеты җитәкчелегенә аның республикага визитын оештырганнары өчен рәхмәт әйтте. Ул Казан һәм Алабугада күргәннәре белән соклануын белдерде. «Казан – Европа илләре, шәһәрләре белән тиңләштерерлек уникаль башкала. Ул төрле, күпконфессиональ, мультимәдәни, актив рәвештә яңаручы кала. Кичә «Алабуга» икътисади зонасына ясалган сәяхәт бездә Татарстанга булган инвестицион кызыксынуны тагын да ныгытты», – диде Паскаль Гёрген.

Конференция кысаларында Европа төбәкләре Ассамблеясе һәм Казан федераль университы арасында үзара аңлашу турындагы Меморандумга кул куелды.

«Европа Союзы һәм Россия арасындагы мәдәни багланышларны истә тотып, академик өлкәдә үзара алмашу, шул исәптән укыту һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең мөһимлеген танып, шулай ук оешмаларыбыз арасындагы һөнәри академик бәйләнешләрнең көчәю мөмкинлегеннән файдаланып, ике як та хезмәттәшлекне үстерү һәм киңәйтү нияте белән әлеге беркетмәгә кул куярга килеште», – диелә документ текстында.

• Чара

3 июньдә Казан федераль университетында «Study at KFU» («КФУда белем алу») дип исемләнгән семинар старт алды.

# Иң әйбәт урын

**Дания ФАТЫЙХОВА,** хәбәрче





Пакистан, Төркия, Кытай, Казахстан, Украина рекрутинг компанияләре белгечләренә югары уку йортының инфраструктур потенциалын бәяләү өчен мөмкинлек туды. Семинар инглиз телендә алып барылды. Тышкы багланышлар буенча проректор **Линар Латыйпов** кунакларга университет эшчәнлеген тәкъдир итте һәм рекрутинг агентлыклары белән килешү төзелгәнлеге хакында сөйләде.

Иран Ислам Республикасы вәкиллеге киңәшчесе **Бехруз Абтахи** (*өстә, сулда*) Казан университеты белән хезмәттәшлектән алынган хис-кичерешләре белән уртаклашты: «Моннан өч ел элек мин үз гражданнарымны укыта алырлык югары уку йорты эзләгән идем. Казан федераль университеты – чит ил студентлары өчен иң әйбәт урын. Биредә үз эшенең осталары укыта, студентларның яшәеше өчен бөтен уңайлы шартлар тудырылган. Хәзер монда безнең 30 магистр һәм аспирант белем ала».

Тышкы элемтәләр департаменты хезмәткәре **Ландыш Закирова** чит ил студентлары өчен документлар тутыру процессы белән таныштырды һәм рекрутинг компанияләре вәкилләренең сорауларына җавап бирде. Алга таба КФУның институт һәм факультет хезмәткәрләре кунакларга презентацияләр күрсәттеләр. Үзләренең бүлекләре турында презентация тәкъдир иткәндә, чит ил студентларында кызыксыну уятырлык урыннарга басым ясап сөйләделәр. Шуны әйтергә кирәк: эшкәртмәләрне төп вуз гына түгел, филиаллар да тәкъдир итте. Мисал өчен, Алабуга институты вузга багышлынган видеоролик күрсәтте, ә Яр Чаллы институты инженерлык юнәлешенә басым ясады.

Визит кысаларында эшлекле кунаклар ике көн дәвамында Фундаменталь медицина һәм биология институты, Физика институты, А.М.Бутлеров ис. Химия институты, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты һәм Филология һәм сәнгать институтының уку аудиторияләре һәм лабораторияләре белән таныштылар.



Алга таба кунаклар Универсиада авылына юл тоттылар. Рекрутинг компанияләр белгечләре КФУ студентлары өчен тудырылган уңайлыклар, шартлар белән танышты.

***Илназ Әхтәмов фотолары***

• 6 июнь – Пушкин һәм рус теле көне

6 июнь көнне Россиядә Пушкин көнен бәйрәм итәләр. 1998 елдан алып, бөек рус шагыйре Александр Сергеевич Пушкинның туган көне дәүләт, илкүләм бәйрәм буларак билгеләп үтелә. 1799 елның нәкъ менә 6 июнь көнендә Мәскәүдә Саша Пушкин туа. Гадәттә, бу көнне шагыйрьнең туган җирләре саналган Пушкин таулары һәм Михайловское биләмәсенә меңләгән кеше агыла. Бәйрәмдә күренекле актерлар һәм музыкантлар чыгыш ясый. 2011 елдан исә, 6 июнь Рус теле көне буларак та бәйрәм ителә башлады. Пушкин иҗатында байлыгы тулысы белән чагылган рус теле 170 миллион кеше өчен туган тел санала, ә 350 миллион кеше аны аңлый. Рус теле илебездә 160тан артык халык һәм милләтнең аралашу теле булып тора. Рус теле – дөньяга иң яхшы сүз осталарын һәм Александр Пушкин кебек даһины биргән бөек әдәбият теле.

# Пушкин һәм Фукс

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты





Сулдан уңга: Л.Ф.Крупенников һәм А.С.Пушкин

Университетыбыз тарихы белән дә А.С.Пушкинның бәйләнеше бар. Дөресрәге, Казан университеты профессоры,, 1823-1827 елларда ректор булып торган Карл Фукс шәхесе белән.

Билгеле булганча, Пушкин Казанга 1833 елның көзендә «Пугачев тарихы» романы өчен мәгълүмат туплау максаты белән килә. Пушкин белән Фукс Энгельгард йортында танышалар. Ул вакытта Фукс – Казан университетының патология һәм терапия профессоры. Өстәвенә, ул җирле тарих буенча белгеч тә була. Ике шәхес арасында баштан ук җылы мөнәсәбәтләр урнаша.

Фукс Пушкинга Казанда Пугачев лагеренең кайда урнашуы хакында сөйләп кенә калмыйча, аны вакыйга булган урыннар белән дә таныштыра: алар бергәләшеп Себер тракты буенча Казаннан 10 чакрым ераклыктагы Троицкая Нокса авылына кайтып киләләр. Пушкин Фуксның хәзерге Киров һәм Г.Камал урамнары киселешендә урнашкан йортында кунак була. Шагыйрь биредә профессорның хәләл җефете Александра Андреевна Фукс белән таныша. Чәй өстәле артында Карл Федорович Казанның пугачевчылар тарафыннан алынуы хакында бөтен белгәннәрен һәм ишеткәннәрен сөйли.

Аннан соң ул үзенең кызыксынучан кунагын Казан аксакалы, кайчандыр Пугачев тоткынлыгында булган сәүдәгәр Л.Ф.Крупенников янына алып барып кайтырга була. Әмма сәгать ярымлык бу сөйләшүдән Пушкин үзенә әһәмиятле мәгълүмат алмый, күрәсең. Пушкин архивында аның Крупенников белән әңгәмәсеннән бер генә өзек тә юк.

Крупенниковтан Пушкин туры Фукс йортына кайта. Авыру янына киткән Фукс югында Пушкин һәм Александра Андреевна рус әдәбияты, шигърияте хакында гәп кора.

Төнге бердә генә Пушкин кунакчыл Фукс гаиләсе белән саубуллаша. «Мин беркайчан да минутлык танышу мондый моңсу саубуллашуга сәбәпче булырга мөмкин, дип уйламаган идем», – ди ул.

Казанга сәяхәтеннән соңгы кичерешләре хакында Пушкин хатынына менә болай дип яза: «Биредә мин картлар, каһарманымның чордашлары белән аралаштым, шәһәр тирә-ягын әйләндем, сугыш булган урыннарны күрдем, барысын язып бардым һәм бу якларга килеп чыгуым юкка гына булмавыннан бик канәгать!» Үзенең «Пугачев бунты тарихы» әсәренең VIII бүлегенең икенче искәрмәсендә ул: «Минем тарафтан Казан университеты профессоры һәм доктор К.Ф.Фукс тыңланды. Биредә сөйләнгән чор турындагы кызыклы мәгълүмат өчен дә мин аңа бурычлы», – дип язып калдыра.

## Экологлар һәм әйләнә-тирә мохитне саклау көне

Без бүген тизлек һәм прогресс заманында яшибез. Шул сәбәпле, табигатьне саклау проблемасы көннән-көн киселәнләшә бара.

Әйләнә-тирә мохитне пычратмау, табигый байлыкларыбызны саклау, киләчәк буынга аның матурлыгын бүләк итү – төп бурычыбыз. Шуны аңлап эш иткәндә генә кешелек дөньясы үз-үзен саклап кала алачак.

- Кешелек тарихы башланганнан бирле планетабызда күпме кеше туган? Якынча исәпләүләр буенча, 2002 елга 106дан алып 140 миллиардка кадәр Homo sapiens дөньяга килгән.
- 2025 елга дөньяның 48 илендә көн күрүче 2,8 миллиардтан артык кешегә су җитмәскә мөмкин. 2050 елга исә бу сан 7 миллиардка җитәчәк.
- Җирдәге төче суның 70 проценты кеше тарафыннан авыл хуҗалыгы кырларын ясалма рәвештә сугару өчен тотыла.
- 1 кг шоколад җитештерү өчен 24 мең литр, 1 кг ит җитештерү өчен – 15 500 л, 1 кг шикәр ясау өчен исә 1500 л су кирәк.
- Җир өслегенең 38 процентына чүлгә әйләнү куркынычы яный.
- 10 елдан соң агулы электрон калдыкларның күләме 500 тапкырга артачак.
- Галимнәр исәпләвенчә, якын киләчәктә 5,5 миллион тере организм юкка чыгарга мөмкин. Фәнгә шуларның нибары 2 миллионы гына билгеле.
- Һәр ел саен глобаль җылыну 350000 кешенең үлеменә сәбәпче булып тора. 2020 елга исә үлем-китем саны 5 миллионга җитәчәк.

• Галимнәребез

# Безнең дә галим!

Акдас Нигъмәт Курат – 15 китап һәм 70тән артык мәкалә авторы. Алар күп телләргә тәрҗемә ителгән һәм бүгенге көндә дә актуаль саналалар, күп кенә югары уку йортларында уку әсбаплары буларак кулланылалар. Аның хезмәтләре, нигездә, Көнчыгыш Европа төрекләре, Госманлы империясе тарихы, Россия һәм Төркиянең үзара мөнәсәбәтләренә багышланган.

Акдас Нигъмәт Курат (22.04.1906 – 8.09.1971) хәзерге Чирмешән районы Бәркәтә авылында туа. Аның әти-әнисе дин эшлекелләре булалар. Башлангыч белемне әтисенең мәдрәсәсендә ала, аннан соң Бөгелмәдә гимназиядә укый. Егерменче еллар башында, ачлык башлангач, чит илгә китеп бара. 1924-1929 елларда Стамбул университетының фәлсәфә һәм тарих бүлекләрендә белем эсти. 1929-1933 елларда Германиядә фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнә һәм 30 яшендә докторлык диссертациясен яклый. Алга таба фәнни эзләнүләрен Швециядә дәвам итә, елдан артык җирле югары уку йортларында лекцияләр укый. Стамбул, Анкара һәм башка университетларда профессор була. 12 телдә (инглиз, алман, француз, рус, гарәп, швед һәм башка) иркен сөйләшә. Бик күп илләрдә лекция һәм докладлар белән чыгыш ясый, үзенең бай тәҗрибәсе белән уртаклаша. Дөньяның күп кенә фәнни үзәкләренә «Мактаулы профессор» булып сайлана. Гомере автомобиль һәлакәтендә өзелә.



Акдас Нигъмәт (уртада артта) хезмәттәшләре галимнәр белән.

Галимнең Көнчыгыш Европа төрекләре тарихына багышланган беренче хезмәте «Печенеглар тарихы» (1937) дип атала. Византия, рус һәм көнчыгыш чыганакларыннан файдаланып, Акдас Курат дөнья тарихына йогынты ясаган печенегларның ролен сурәтли. Автор шул чорның иҗтимагый-сәяси төзелешен һәм бай мәдәниятен дөрес тасвирлауга йогынты ясый.

«Топкапы Сарае Стамбул музее архивында сакланган Алтын Урда, Кырым һәм Төркстан ханнарының ярлыклары һәм битикләре» (1940) хезмәте чын мәгънәсендә фәнни ачышка әверелә. Галим Алтын Урда ханнары һәм Төркстан хакимнәренең ярлыкларын һәм хатларын табып кына калмыйча, аларны тикшерә һәм бастырып та чыгара. Акдас Куратның тырышлыгы аркасында, бөтен дөнья төрки тарихының шундый бай хәзинәсе белән таныштты, диярга мөмкин.

Галимнең рус-төрек мөнәсәбәтләре тарихына багышланган зур хезмәте «Төркия һәм Россия» (1970) дип атала. Анда төрле тарихи вакыйгаларга бай булган 1798-1919 ел аралыклары урын алган.

Куратның кайбер хезмәтләре Татарстан республикасы Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана. Бу эшләр тәрҗемә ителмәгәнлектән, алар белән эшләве бераз кыенлык тудыра.

«Безне ерактагы максатыбызга нинди юллар китерә ала? Җиңел һәм алдан салынган юллар юк ул. Аның өчен бары тик тырышып эшләргә генә кирәк», – дип яза галим. Акдас Нигмәт Курат шәхес буларак та, тарихчы буларак та соклану хисе уята. Кызганычка каршы, аның хезмәтләре аз өйрәнелгән һәм билгесез булып кала бирә. Аның Татарстан тарихын өйрәнүгә һәм, гомумән, тарих фәне үсешенә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Галимнең тикшеренүләреннән чыгып, Куратны татар мәгърифәтчеләре башлап җибәргән эшнең (безнең бай тарихыбызны өйрәнү) дәвамчысы дип әйтеп була. Акдас Нигъмәт Курат – танылган мәгърифәтчеләр һәм совет чорыннан соңгы талантлы тарихчыларны бәйли торган буын вәкиле.

• Чара

Шушы көннәрдә Россия тәрҗемәчеләре союзының VIII съезды узды.

# Дәрәҗәбез арта

Россия тәрҗемәчеләр союзы әдәбиятның бөтен жанрларында, рәсми документация, массакүләм матбугат чаралары, лексикография өлкәсендәге тәрҗемәчеләрне берләштерә. Аның әгъзалары булып Россия тәрҗемәчеләре генә түгел, ә чит ил вәкилләре дә тора. Чарада Филология һәм сәнгать институтының тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Әлфия Йосыпова, рус филологиясе бүлеге мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор Резедә Мөхәммәтшина катнашты. Съездда катнашучыларны Россия тәрҗемәчеләре союзы президенты Леонид Гуревович сәламләде. Ул чыгышында Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты укытучылар коллективын союзга алынулары белән котлады һәм югары квалификацияле тәрҗемәчеләр әзерләүдә зур уңышлар теләде.



Сулдан уңга: Р.Мөхәммәтшина, Л.Гуревович, Ә.Йосыпова.

• Сәламәтлек

# Куркыныч матурлык

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Сезнең дә журнал битләрендәге, телеэкраннардагы «йолдызларга» карап, сокланып: «Эх, мин дә шундый булсам иде», – дип авыр сулап куйганыгыз бардыр. Беренче карашка бөтен яктан идеаль булган кешеләргә охшаш булу теләгендә бернинди начарлык та юк шикелле. «Чибәрлекнең чиге булмый», – дип болай гына әйтмәгәннәрдер аны. Тик кайбер вакытта бу «чиксез» теләк куркыныч нәтиҗәләргә китерә шул.

Көнләшү хисе Лилиягә (исеме үзгәртелде) гомер буенча таныш иде. Башта балалар бакчасында, аннары мәктәптә. Унҗиде яшьтә бөтен кызлар кыска итәкләр, матур күлмәкләр кия башлаганда, ул көчкә зур размерлы джинсыларына сыя иде. Егетләр белән дә Лилия аралашмады: «Минем сыман кыз белән кем йөрсен инде, әнә нинди чибәрләр белән дөнья тулган бит», – дип әйтә иде үсмер. Үз тәнен бөтен күңелдән күрә алмаучы кыз, һичшиксез, ябыгырга булды. Һәм, иң мөһиме, бик кыска вакыт аралыгында.



Үз хыялын тормышка ашыру өчен, Лилия, беренче чиратта, интернетка керде. Үзенә ошаган диетаны сайлап алды һәм яңа тормышка беренче адымнарын ясый башлады. Тик, ике атна узгач, ул бары тик 3 килограммга гына ябыкты. Мондый нәтиҗә Лилияне, әлбәттә, канәгатьләндермәде һәм кыз үзен башта алтыдан, ә аннары сәгать дүрттән соң ашаудан чикләде. Өстәвенә физик йөкләмәләрне дә мөмкин кадәр арттырды: йөгерде, җәяү йөрде, фитнес белән шөгыльләнде. Болар белән генә дә чикләнмичә, ябыгу өчен төрле чәйләр эчеп, атнага 3 көн бөтенләй ашамады. Коры сөяккә калуына карамастан, кыз барыбер ябыгу хисе белән янды. Көннәрнең берсендә Лилиянең горурлыгы – чәчләре бик нык коела башлагач, әти-әнисе табибларга мөрәҗәгать итте. Кыз барыбер үзенекен эшләде. Гомер буена аның белән дустанә мөнәсәбәттә булмаган абыйсы Интернеттан анорексия белән чирләгән кызларның фотоларын күрсәтеп: «Минем синең кабереңянында елап торасым килми», – дигәч кенә Лилия бераз уйланып калды һәм табибларга мөрәҗәгать итте. Шөкер, кызга хәзер 20 яшь. Үз гәүдә төзелешеннән ул канәгать, тик, анорексия белән чирләгәннән соң, 2 елга якын башы хастаханәләрдән чыкмады. Сәламәтлеге бик нык какшады.

Лилия белән булган хәлләр бүгенге көн өчен табигый. Интернет челтәренә кереп карасак, анорексия дигән сүзгә бер миллионга якын битләр ачыла. Скелетка калган кызлар, аларның тормышы, хис-кичерешләре... Фотосурәтләр астында фикерләр дә бик күп. Мәсәлән, анорексия белән чирләүче кызлар өчен махсус сайтта миншундыйрак фикерләрне таптым: «Ни өчен үз сәламәтлекләрен бетереп йөриләр инде алар», «Баш эшләми боларның, безнең җәмгыятьтә аларга урын юк». Кызганычка каршы, кызларны җәлләүче, аларча эшләргә теләүче кешеләр юк диярлек. Барысы да аларны сүгә, беркем дә мондый адымга ни өчен баруларын аңларга теләми.

Ә проблеманың асылы җәмгыятьтә ята бит. Тазарак, берәр җире белән икенче кешедән ким булган кешеләргә без ни өчендер икенче күзлектән карыйбыз. Бу балалар бакчасыннан ук килә. Мәктәп турында әйтсәң дә юк: «Тонна», «Юан, таза», «Ямьсез» дигән сүзләрне үсмерләрдән еш ишетергә туры килә. Әле психикасы тулысынча формалашмаган кешедә бу сүзләр начар хисләр уята. Кызлар еларга тотыналар, үз-үзләрен яратмый башлыйлар. Егетләр исә тормыштан читләшәләр, дуслырсыз калалар. Минә шундый кешеләр бер мизгел килеп җиткәч, көлүләрдән туеп, я тормышлары белән хушлашалар, я диетага утыралар. Ә соңгысы еш кына «анорексия»гә әйләнә.

Әлбәттә, бөтен гаепне җәмгыятькә генә сылтарга ярамый. Еш кына хатын-кызлар, бик чибәр булсалар да, үзләренең кыяфәтләреннән канәгать түгел. Аңа өстәп, Интернет, матбугат битләрендә бер атна эчендә 3-4 кг га кадәр ябыктыра торган диеталар турындагы белдерүләр, төрле «файдалы» киңәшләр кызыктыра бит. Ә хатын-кызлар чибәрлеккә омтылуда бөтен авырлыкларга да түзә. Сүз юк, үзеңне формада тоту, матур булырга теләү – яхшы сыйфат. Әмма 14-18 яшьтә нинди диета турында сүз барырга мөмкин? Ә кызганычка каршы, гүзәл затлар менә шул вакытта ябыгу белән саташа башлыйлар да инде. Статистика буенча, хәзерге заманда 14 яшьтән алып 20 яшькә кадәр булган кызларның 4 проценты бу чирдән котыла алмый.

Һичшиксез, бу проблема турында күп язарга мөмкин. Берәүләр шундый кызларны аңламасалар, икенчеләр аларның урыннарында булып та карадылар инде. Тик үзеннән-үзе бер сорау туа: ни өчен шуның кадәр ябыгып, үз сәламәтлегеңне бетерергә? Ниндидер чикләр булырга тиеш бит. Бәлки, бирелгән матурлыкның кадерен белеп яшәргә кирәктер?

• Әй, язмыш

# Мин – авыл баласы!

**Илмира АХУНОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Башкалада яшәүче халыкның өчтән бере – авылдан килгәннәр. Танылган галимнәребез, җырчыларыбыз, башка сәнгать кешеләре – «авыл балалары». Моңа да карамастан, элек-электән халыкны «шәһәрнеке» һәм «авылныкы»на бүлеп карау гадәткә кереп калган.

Дөрес, хәзер инде бу ике төр кешеләрне берберсеннән аеру авыр, чөнки авылда да тормыш шәһәрнекеннән ким түгел. Яшәү шартлары яхшы, заманча технологияләр кулланыла. Шулай да аермалар да бар. Авыл мәктәбен тәмамлап, Казанга укырга килгән яшьтәшләрем арасында: «Шәһәр тормышына күнегүе авыр. Житмәсә «авыл баласы» булу да үзен сиздерә, диючеләр бар. «Шәһәрләр», һаваланып, «авылныкыларны» кыерсытырга да, аларның күп нәрсәне әле аңлап бетермәвеннән көләргә дә күп сорап тормыйлар кайчак. Янәсе «текә»ләр. Тик бөтенесе дә түгел, араларында, киресенчә, шәһәр белән танышырга ярдәм итүчеләре дә бар. Ә мәркәзебез Казанга халык агылып кына тора. Аеруча яшьләр, «авыл яшьләре»:

«Хыяллардан канат үреп, әллә нигә якын күреп,
Төрле яктан җыелганбыз
шушы шәһәргә.
Беркем көтеп тормаса да,
язмыш безне сынаса да куркып калмадык...» – дип җырлый бит яраткан җырчыбыз Зиннур да «Без авыл егетләре» дигән җырында. Авыл егетләрен Казан ничек каршы алды икән? Килгәннәренә үкенмәгәннәрме? «Авыл баласы», – дип кыерсытып караучылар булмаганмы? Бу сорауларны аларның үзләренә биреп карадым.

• **Зөлфәт Зиннуров (җырчы):** «Кыерсытучылар булмады, чөнки «общага»да тордым. Анда барыбыз да авылныкылар. Үкенмәдем, әлбәттә! Ә мәктәптән чыгып киткәндә, Сабага кайтам дигән идем».

• **Әбри Хәбриев («Татар радиосы» ди-джее):** «Мәркәзебез мине киң колач җәеп каршы алды, дияр идем. Үкенергә ярамый, дип өйрәттеләр мине. Үкенеп, бер вакыйганы да үзгәртеп булмый. Авыл баласын кыерсыту бик кыен ул. Без бит шәһәр балаларына караганда күпкә ныграк һәм чыдамрак. Ә болай алганда, шәһәр ул яшәү урыны түгел. Шәһәрдә эшләп, карьера ясап, күңел ачып була, ләкин яшәве авыр. Шуңа күрә дә мин хәзер авылда көн күрәм».

• **Инсаф Сафиуллин (КФУ студенты):** «Йокламый торган төннәре, шау-шулы урамнары булган тынгысыз шәһәрдән авылга гел качасы килде башта. Үкенмәдем, каршы алучы дуслар да бар иде минем ул вакытта, хәзер дә бар».

• **Илһам Вәлиев ( КФУ студенты):** Дөресен генә әйткәнгә, Казанга килгәндә, минем монда дусларым бар иде. Башкала мине җылы кочагына ук алды, дип әйтә алмыйм. Килгәнемә дә үкенмим, киресенчә, мин бик шат. Авыл баласы дип кыерсытмадылар. Алар әйткәнче үк, «мин авыл баласы», – дип авызларын томалый идем.

• Киңәш-табыш

# Файдалы ял итәбез

Киңәшче ролендә
**Ләйсән ИСХАКОВА**

Ниһаять, зарыгып көтеп алынган җәй килеп җитте. Студентлар өчен быелгы каникуллар нәкъ бер айга озынрак булачак. Ә нигә әле шушы вакытны үзең өчен файдалы итеп үткәрмәскә? Һәр көнең мәгънәле һәм кызыклы булсын дисәң, киңәшләребезгә колак сал!

### Чит тел

Әлбәттә, бер җәй эчендә генә чит телне тулысынча өйрәнеп бетерү мөмкин түгел. Шулай да аерым сүзләрне ятларга һәм әйтелеш өстендә эшләргә вакыт та, мөмкинлек тә бар!

### Спорт

Гәүдә төзелешеңә дә игътибар итәргә вакыт житте. Җәй физик күнегүләр өчен менә дигән чор! Әлбәттә, өч ай эчендә генә атлетка әйләнеп китү икеле, шулай да киләчәк физик үсеш өчен, бу бер этәргеч булып торачак. Тартылу, пресс күнегүләре, чүгәләү – гәүдәне тонуста тоту өчен төп нигез. Иртә белән йөгерү дә файдага булачак.

### Китап

Төрле яклап үсәргә тырыш – төрле жанрдагы китаплар укы. Китап уку – елның һәр фасылында да баш мие өчен менә дигән күнегү.

### Походка чыгу

Дусларыңны җыеп, су, азык-төлек, палатка һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин ител дә, юлга җыен. Табигатьтәге ял – иң шәбе.

### Су коену

Урамда эссе, тынчу, ә яңгыр әле яварга җыенмый? Димәк, су коену өчен менә дигән мөмкинлек! Сөлге ал, коену киемнәрен ки дә, дусларың белән бергәләп якындагы сулыкка ашык. Йөзә белмәсәң, өйрәнеп кара.

### Бию

Җәй – биергә өйрәнү өчен дә иң кулай вакыт. Бию – тормышыбызны күңелле һәм кызыклы итүдә иң әйбәт чара. Үзең яраткан музыканы кушып куй да башла: сикер, төрледән-төрле хәрәкәтләр ясa, актив бул! Шуны да истә тот: импровизация – уңышлы биюнең төп нигезе.

### Башкаларга ярдәм ит!

Һәр көн саен күршеләреңә, дусларыңа һәм туганнарыңа ярдәм кирәк булып тора. Үзең турында гына уйлаудан туктап, башкаларга үз ярдәмеңне тәкъдим итәргә ашык!

### Гитара

Күптәннән нинди дә булса музыка коралында уйнарга хыялланасың? Димәк, бу хыялны тормышка ашырыр чак житте! Гитара яки башка уен коралында уйнарга өйрәтү курсларына язылып кайт.

### Велосипед

Велосипедта йөрү дә сәламәтлек өчен файдага булачак. Дусларың белән бергәләшеп, велосипедка утырып паркка яки су керергә бар!

### Безнең кече туганнарыбыз

Үзеңә нинди дә булса «дус» ал! Эт, песи, кенәри, я булмаса, аквариум балыклары һәрвакыт кәефеңне күтәреп торыр. Өстәвенә, аларга күрсәтелгән кайгырту, игътибар кемгә дә булса кирәклегең турында искә төшереп торачак.

### Күңел ачу

Клуб, дискотека, күргәзмә, музей, театр, кинога йөр.

Бу җәйдә яңа туган һәр көнгә сөенеп яшәргә тырыш. Көннәр буе өйдә утырма. Хәрәкәтлән, селкен, актив бул! Онытылмас мизгелләр, җылы матур җәйләр һәм яңа дуслар үзеңә!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.